


Чаян

ISSN 0136-7110

САТИРА ҺӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ * АВГУСТ * 2016 * КАЗАН

14



– Әйдә, эчеп бетер дә, киттек — караңгылана башлады инде!

Виталий ФЕОКТИСТОВ

АННАН-МОННАН
ИНФОРМ
СОҢГЫ ХӘБӘРЛӘР

- НАТО илләренең берсендәге фетнә аркасында НАТОның кичектергесез бер киңәшмәсендә, хәрбиләр, НАТОга кергән бер иленә сыеныр урын сорап йөргәч, НАТО илләре НАТО илләреннән Рәсәй агрессиясеннән саклану өчен ныграк берләшүгә чакырганнар.
- ИГИЛ, EURO-16 да Рәсәй футбол җыелма командасы чыгышы өчен җаваплылыкны үзенә алган.
- Химиянең иректе радикалларга багышланган бүлеге экстремистик дип кабул ителгән.
- Рәсәйдә яңа министрлык барлыкка килгән — Роспокемоннадзор.
- Илдә кризис булу сәбәпле, "Өйдә ашыйбыз" дигән телевизион тапшыру хәзер "Кунакта ашыйбыз" дип аталачак.
- Казанда уртача хезмәт хакы 28 меңгә җитте. Анда яшәүләренә карамастан, шунда күчәселәре килә хәтта.
- Ватаныбыз авиакомпанияләре, очып киткәндәге һәм очып төшкәндәге алкышлар өчен, тарифлы түләү кертмәкче булалар.
- Киевта гей-парад саклаучы полицейскийларның ун резина тәпәчләрен урлаганнар.
- Кырларда борчак өлгерү сәбәпле, шәһәр арты трассаларында аварияләр күбәйде.
- Авыру, поликлиникада чиратта торган арада, "Война и мир" романының дүрт томын да укырга өлгергән.
- Түләүле клиникаларга йөрүчеләргә башта ук авыртуны баса торган укол ясыйлар, бу алга таба түләү кыенлыгын, ягъни йөрәк әрнүен киметә икән.
- Гипермаркетларда сатып алу күләмен арттырып күрсәтү өчен, бәя күрсәткечләрендә иртәгесе бәя куела.
- Сатуда: "Сез анда нык торыгыз!" дип язылган акча янчыклары барлыкка килде.
- Мәктәп укучысы, физкультурага йөрмәс өчен, мельдоний кулланган.
- Хоботы белән селфи эшләүче филне күргәннәр.



Виталий ПОДВИЦКИЙ



ШОМБАЙ
болай диде...

Хөрмәтле Чаян! Көн саен өстебезгә килеп торган яңалыклар ташкыныннан мине берсе аеруча гаҗәпләндерде. Телевидение ясаучы осталар «Тыныч йокы, нәниләр!» тапшыруын алып баручы итеп элекке боксёр-профессионал, хәзерге депутат Николай Валуевны билгеләгәннәр. Аны күргәннән соң балалар ничек тынычлап йоклап китәр икән?


Р. МӘҖИТОВА

АЗНАКАЙ

– Тапшыруда яңа спонсор – балалар өчен памперслар җитештерүче барлыкка килгән, күрәсең, – диде Шомбай ага бу яңалык турында ишеткәч.



Валерий ТАРАСЕНКО



Игътибар, акция! Өч әйберне дүрт әйбер бәясенә алган кешегә берсе бүләк итеп бирелә.

Ритуаль хезмәт фирмасына үз клиентлары булган менеджер кирәк.

«Вирус» техник ярдәм хезмәте. Компьютерлар һәм кәрәзле телефоннар ремонтлау.

Игътибар! Базар территориясендә фейс-контроль эшли.

Хөрмәтле ханымнар! Мунчаның хатын-кызлар бүлегенә өч яше тулмаган ир-атларны алып килергә ярый. Администрация.

Пенсионерлар игътибарына! Пенсия ташламасы таныклык һәм тере пенсионер булган очракта гына эшли.

Хөрмәтле сатып алучылар! Бәяләр белән бәйле хис-кичерешләрегезне тышка чыгармагыз. Үзебез дә аптырашта!

(белдерүләрдән)

ЮККА ӘЙТМӘСЛӘР

Без яшәмибез, ә гомер буе яшәргә әзерләнәбез генә.

• • •

Көннәрне санарга түгел, ә үлчәргә кирәк.

• • •

Сөйлисең икән — йә кыскарак, йә күңеллерәк сөйлә.

• • •

Медицина безне озаграк һәм газаплырак итеп үләргә мәҗбүр итә.

• • •

Фән ул – фаразлар зираты.

• • •

Дөньяда тотрыксызлыктан да тотрыклырак әйбер юк.

• • •

Бөтен кешенең дә озак яшисе килә, ләкин беркем дә картаерга теләми.

• • •

Без авырганнан түгел, ә яшәгәннән үләбез.

Зыялылар мәҗлесендә язып алынды.

Василий ШИМБЕРЕВ

BREXIT

Әйе, үзебездә әшәке сүзләр аз иде. Тагын менә «брекзит» дигәне барлыкка килде. Кемгә ничектер, ә миңа аның мәгънәсе аңлашылмый. Начармы бу, әллә бик начармы — шайтаным белсен.

Телевизордан аңлаткан булалар, әлбәттә, тик аларның сүз боткасыннан һәм шау-шоуларыннан күз томалана һәм баш авырта.

Берәрсе чыксын да һәм турыдан-туры ярып салсын иде: сезнең «брекзит»ыгыз безнең бөртекләләр уңышы һәм савымнарның артуы өчен булды ни дә, булмады ни! Ә аягыңа берәр авыр нәрсә төшкәч, «анаңны брекзит итим!» – бөтенләй башка нәрсә. Йә булмаса, коймага бертуганга әйләнеп беткән өч хәреф урынына «брекзит» дип язсалар иде. Һәм шунда ук бөтенесе үз урынында, бөтенесе аңлашыла!

Ә һаман баш катыралар – инглизләрнең фунты төшә, Шотландия азатлык таләп итә, Евросоюз безнең Союз шикелле таркалырга җыена. Туйдырып бетерделәр, тәгәрәсеннәр иде бөтенесе дә чуртымның брекзитына!

Илдус АЗИМОВ





Ятьмәләр һәм беркетмәләр

Хәзер балаларны гына түгел, өлкәннәрне дә Интернеттан аерып булмый. Челтәрдә буталып йөрү ошый аларга. Тик “челтәрче”ләрнең мохите виртуаль дөнья белән генә чикләнми. Аларның челтәрнең су астындагы төре — ятьмә белән мавыгучылары да җитәрлек. Ул ятьмәгә бер берексәң, рыбнадзор ярдәменнән башка ычкынам димә...

Мисал өчен, Казанда яшәүче Сергей Пашагинны алыйк. Соңгы алты ай эчендә генә ул Рыбохран инспекторлары беркетмәләрендә дистәләгән тапкыр искә алына. Сәбәбе — бу болганчык суда балык тотарга яратучының уылдык чәчү чорында язгы Иделгә даими рәвештә ятьмә салуы.


Беренче тапкыр аны апрельдә, елга өсте боздан әле арынып кына килгән чакта тоталар. Ул чакта ятьмәче чагыштырмача кечкенә штраф — ике мең сум түләп котыла. Мондый “тотым”нан соң уылдык сезоны беткәнчегә кадәр булса да, ятьмәне төреп, киштәгә алып куясы бит югыйсә. Юк шул! Бер атна да үтми, балыкларның имин тормышын саклаучылар тагын офыкта иске танышларының шәүләсен күреп алалар. Ул берни булмагандай, ашыкмыйча гына, ятьмәсеннән берсеннән-берсе зуррак балыклар алып маташа. Бу юлы инде штраф биш меңгә тарта. Ләкин браконьер-рецидивистны бу чара да туктата алмый. “Тоттым, тотам һәм тотачакмын!” — дип белдерә Пашагин инспекторларга чираттагы тоткарлану вакытында. Ул вакытта инде аңа язылган штрафларның гомуми суммасы егерме биш мең сумнан артып киткән була.

Әйтеп торасы да юк, егет ятьмә тозагына нык эләккән булып чыга. Хәер, ул гына түгел. Ел башыннан Татарстан елгаларында ике меңнән артык браконьер тоткарланган. Кайберәүләре берничә тапкыр. Мисал өчен, Мамадыш районының Камский Леспромхоз бистәсендә яшәүче Александр Москвин рыбнадзор ятьмәсенә ел саен эләгеп тора. Бу сезонда да ул иялнгән гадәтеннән читкә тайпылмады — инспекторлар аны елга киңлекләрендә чираттагы тапкыр ятьмә салган чакта тоттылар. Законсыз балык чиртүче бу балыкчы чал Чулман суларында үзен балык кебек тоя, ахрысы. Аңа һәм кәсептәшләренә текә дулкыннар да, инспекторлар да, штрафлар да куркыныч түгел бугай...

Инде сүз киткән икән, штрафлар турында. Браконьерларның күбесе аны вакытында түләүне кирәк дип тапмый. Ә бит озак түләмәгән штрафларның күләме икеләтә артуы мөмкин! Бу очракта инде законсыз тотылган балыкның үзкыйммәте турында да уйлана башларга туры килмәгәе...

Айдар СУБАЕВ

Илдар НӘФИЕВ



Александр КОСМЫЛИН





Михаил ЛАРИЧЕВ



Александр КОСМЫЛИН





• • •

Бүген банктан кредитка түләү срогы үткәнлек турында СМС килде... Җавапны болай дип яздым: “Акчам юк! Ләкин сез бирешмәгез!”

• • •

— Рәсәй халкының телефоннан сөйләшүләренең 92% — буш лыгырдау, — дип хәбәр итә ФСБның социологик хезмәт күрсәтү бюросы.

• • •

Игътибар! “Классташлар” сайтын кулланучылар. Үтенеп сорыйбыз, сез үзегезнең кыйммәтле коттеджларыгыз һәм машиналарыгыз янында фотога төшкәндә, сурәтләрегезне яшәгән урамыгыз, йортыгыз һәм машинагыз каршында күрсәтеп эшләгез, инспекторларның кадерле эш вакытларын әрәм итмәвегезне үтенеп һәм алдан ук рәхмәтебезне белдереп, Сезнең Салым Инспекциягез.

• • •

— Рәсәй Пенсия фондындагы дефицит проблемасын ничек итеп хөкүмәткә чишәргә?

— Моның өчен бары тик пенсия яшен 75 кә күтәрергә кирәк.

— Һәм шуннан нәрсә була?

— Ул вакытта Пенсия фонды үзе дә кирәк булмаячак.

• • •

Кешеләрнең мул тормышта яшәүләре аларның тавыклары аша беленә — берәүләрнең акчасын тавык та чүпләми, икенчеләренең — берәмтекләп ашыйлар... Ә күпләрнең кереметннән тавыклар көлә.

• • •

Әгәр дә түрәләр артыннан Бердәм дәүләт имтиханы (ЕГЭ) бирә торган мәктәп укучыларын күзәткән кебек күзәтсәләр, ул чагында безнең илебез дөньяда иң беренче булыр иде.

• • •

— Нәрсә белән мәшгуль?

— Пасьянс таратам.

— Компьютер сатып алдың мәллә?

— Юк, бу атнада носкиларымны юдым.



МӘГАРИФ ҖИМЕШЛӘРЕ

Казанда шәһәр кешеләренең аз укуы турында борчыла башлаганнар. Һәм киң халык массаларын мәгърифәт нурына тартырга карар кылынган. Казансу ярында, ачык һавада урам китапханәсе ачып җибәргәннәр. Оештыручылар фикеренчә, һәр теләгән кеше эскәмиягә утырып китап уку, шулай ук китапханәне үз китаплары белән тулыландыру мөмкинлеге алырга тиеш булган. Ләкин беренче көннәрдә үк кырыс чынбарлык изге теләкләрне чәлпәрәмә китергән. Билгесез "укучы"лар куелган китапларны күпләп-күпләп билгесез юнәлештә шудыра башлаганнар. Аптырашта калган оештыручылар видеокүзәтү камералары урнаштырырга һәм китап сөюче замандашлары турындагы фикерләрен үзгәртергә мәҗбүр булганнар.

СУ САКЧЫЛАРЫ

Красноярск краендагы Ачинск шәһәренең "Теплосеть" компаниясе җитәкчеләренең башында берзаман өстәмә табыш алу турында фикер туа. Һәм моның өчен алар шәһәрдәге су үткәргеч колонкаларыннан бушлай файдалануга каршы көрәш ачалар. Ял көннәрендә һәр колонка янына "күзәтүче"ләр куела. Алар су алырга түләү квитанцияләре булганнарга гына рөхсәт итәргә тиеш булалар. Коммуналь шантаж кыргыйлыкка барып җитә – бушлай файдаланылган колонкаларны сүтә башлыйлар. Исәпләп чыккан саннар буенча, су сакчыларының хезмәт хакы алынган суның бәясенә тәңгәл булып чыга.

КҮҢЕЛСЕЗ ХЕЗМӘТ

Француз Фредерик Дезнард үзенең хуҗасыннан... күңелсез эш өчен 360 мең евро күләмендә компенсация таләп иткән. Парфюмерия компаниясендә эшләүче Фредерик фикеренчә, җитәкчелек аны шулкадәр аз эшләргә мәҗбүр иткән ки, ямансу һәм төксе вакыт уздыру сәбәпле, сәламәтлегенә зыян китергән. Их, безгә булса иде алар кайгысы! Ачтан үлмәслек хезмәт хакын вакытында алу өчен безнең халык теләсә нинди караңгы уйлар белән әллә нинди эшләр башкарырга әзер бит...



Игорь КИЙКО



Алексей БУЛАТОВ



Николай ВОРОНЦОВ



МЕНӘ СИҢА МӘСЬӘЛӘ!

Кешеләр әйтүенчә, уку – яктылыкка илтә. Ә менә дәреслекләр – караңгылыкка! Аларның кайберләрендә язганны укыгач, балаларның психик халәте өчен курка башлыйсың.

Әйләнә-тирә мохит дәреслеген төзүче Кафканы бик күп укыгандыр, күрәсең. Ул балалардан дөньяны чикерткә күзләре белән күрүне, яфракның һәм дулкынның селкенүен, бакаларның җырлавын һәм карның шыгырдавын рәсемгә төшерүен сораган.

Икенче дәреслектә рәсемнәр буенча балаларның күпме яхшылык порошогы ашаганын билгеләү соралган. Тагын менә мондый мисал: “14 бала йөзәргә өйрәнгән. Өчесе әле йөзә белми, ә икесе инде баткан. Ничә бала йөзәргә өйрәнгән һәм әлегә батмаган?” һәм мондый “креатив” мәсьәләләр бик күп. Әллә бу дәреслек төзүчеләр акылга сай, әллә бу китаплар баладан чи надан ясарга чыгарыла.

Тагын бер мәсьәлә: “Җүләрләр йортында баш табиб һәм күп җүләрләр бар. Атна дәверендә һәр җүләр көнгә бер мәртәбә кемне дә булса тешләгән (үзен тешләргә дә мөмкин). Атна ахырына һәр авыруны икешәр мәртәбә тешләгәннәр, ә баш табибны – йөз мәртәбә. Шифаханәдә ничә җүләр бар?” Тәртипкә бик үк туры килеп бетмәсә дә, сорауга сорау белән җавап бирик әле: «Безнең балаларны ничә җүләр укытырга маташа?»

• • •

Анасы малаен сүгә:

– Ничек оят түгел сиңа мәктәптә үзеңне шулай тотарга! Атаңнан үрнәк алыр идең, ичмасам!


– Төрмәдә утырган әтидәнме?

– Алай димә, улым! Әле менә соңгы хатында «үземне яхшы тотканым өчен иртәрәк чыгарачаклар», дип язган.

Сергей АНДРИАНОВ



Андрей САЕНКО











«ЧАЯН»НЫҢ
АЛТЫН САНДЫГЫННАН

Гамил АФЗАЛ

БЕЗНЕҢ БРИГАДАДА

Тимершәех, тибеп куйса, тимер өзә,
Тыйнак шул ул, әдәп саклый, типми генә.
Кәнсәләрдә нәрәт яза, саннар тезә;
Интекмичә яшәп ята ипле генә.

Бакый абзый, басып куйса, бакыр өзә,
Басса өзә, көчен җәлли, басмый шул ул.
Пожарник ул, белмәсәгез, — әйтим сезгә,
Көннәр буе каланчасын саклый шул ул.

Салих абзый батыр кеше, Салсал кебек,
Кәеф өчен печтек кенә салган кебек.
Каравылда челем тарта, муенын кашый,
Тир түкмичә, рәхәт кенә тыныч яши.

Кадыйр абзый кладовойда (әйтсәм ярый)
Капчык саный, капчык ямый, капчык карый.
Усал телләр аның кулын кыек, диләр,
Булса булыр, сөйли бирсен гайбәтчеләр!

Барый агай бүрек тегә, бүрек сата,
Иматетдин имин генә итек баса.
Такта ярып, акча табып йөри күпләр,
Калганнары төрле җирдә начальниклар.

Уттай кызу урак өсте, печән өсте,
Арсландай иргә кулай авыр эшне
Тирләп-пешеп, янып-көеп эшләп бара
Әби-җиңги, түти-апай, бала-чага.

Әнвәр МОТЫЙГУЛЛИН

БҮРЕЛӘР БЕЛӘН ЯШӘҮ

Мин үземә бүре алырга булдым. Ә нәрсә, минемчә, бик яхшы фикер. Кем белә, бәлки берәрсенең миннән бурычка акча аласы яки өйне басасы килер?

Гомумән, бүре — искиткеч уңайлы нәрсә! Менә әзрәк өйрәтәм дә — ул минем урынга кибетләр буйлап йөри башлый. Авызына ит кисәге капкан бүредән акча сорау бер сатучының да башына килмәс дип уйлыйм. Йә затлы кабымлык белән коньяк. Ә бүре кирәк нәрсәне эләктерә дә — туп-туры өйгә!

Ә тагын урамда чыгышлар ясарга була. Бүрене юлга аркылы утыртасың да, туйганчы җырла, бие... Кешеләр үтеп китәр өчен йөзәр тәңкә сала башлаганчы...

Хатын белән теща да бераз тынычланыр. Мине кимерергә тотындылармы — бүрем аларга карап кына куя! Шунда ук икесе дә шым була...

Ә транспортта күпме экономия ясарга була! Эш буенча йөрергә дә була, болай гына да. Бернинди "бөке" юк, номерсыз-нисез, техосмотрсыз йөрергә була. Берәр гаишник-мазар минем бүрегә штраф салырга маташып кына карасын — үзе кызыл утны гына түгел, акны-караны күрми чабып китәчәк!

Эштәгесен инде әйтәсе дә юк... Менә мин фирмага тиешеннән ике-өч сәгатькә соңарып килдем, ди. Нәчәлникнең авызын ачуы гына була: "Син кайда, фәләнфәсмәтән, йө..." Ә мин шалт — бүремне аның каршына! Биш секундтан инвалидность буенча пенсиягә китәчәк! Аннан соң, бүрене җилтерәтеп, генеральный янына! Янәсе, эшчәнлегегез профессионализм ягыннан аксау сәбәпле, урыныгызны калдырырга теләмисезме? Без бүре белән директор булып китәбез. Мин — генеральный, ә ул — тәртип буенча урынбасар. Вәт фирмада тәртип булачак!

Шәп булыр идә дә бит, тик бүресен каян табарга? Янәшәдә генә, Мари урманнарында кайчандыр булган диләр, хәзер юкка чыкканнар... Кайберләре хәтта кешелеккә чыккан, дип сөйлиләр... Бәлки, шуңа күрә дә без чын бүреләр кебек яшибездер дә... Кайчагында улап та куясы килгәли...





Михаил НИКИТИН

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

Кешеләрне бәрнәрсә дә коммуникация чаралары кебек читләштерми.

Яңа телевидение технологияләре күз күрәсе килмәгән нәрсәләрне сыйфатлырак итеп күрсәтә.

Без ярлы кешеләргә бай.

Өмет — тормышның яртысы, өметсезлек — үлемнең яртысы.

Берәр нәрсә камиллеккә җитә икән — яңа технологияләр кертелә башлый.

Кризис чорында без бәйрәмчә киенәбез, чөнки көндәлек кием инде тузып беткән.

Аеклык – тормыш нормасы. Һәм үзенең нормасын һәркем белергә тиеш!

Тормышның үзен аның мәгънәсенә караганда ныграк яратырга кирәк.

Әгәр яхшы әйберне яхшыртсаң, булганыннан да начаррак килеп чыга.

Яшәү ул — һөнәр. Кызганычка каршы, күпләр һәвәскәрлек белән шөгыльләнә.



Югарырак, тизрәк, сәясирәк!



Отто ХОЙЗИНГЕР



Риодагы Олимпиаданы башланганчы ук гаугалы, җәнҗаллы дип атарга була. “Урыс допинг”асы тирәсендәге кызышлар, әләкләүләр, ВАДА докладындагы су кушулар, гаепсезлегеңне исбат итүне кире кагулар, безнең спортчыларны дисквалификацияләүләр, спорт түрәләренең булдыксызлыгы, аларның әлеге вазгыятьнең масштабын бәяли, аныклый алмаулары, Елена Исинбаеваның яшьләре...

Менә шундый “йөк” белән киттеләр безнең спортчылар Риога. Һичшиксез, 2016 елгы Олимпиадада аларны бик үк мәрхәмәтле допинг игътибары көтеп тормас. Мораль басым, бәлки көндәшләренең җанатарлары да төрле әшәкелекләр эшләргә әзер торырлар. Безнекеләр алдында бер генә бурыч кала: үзең өчен генә түгел, Олимпиадага килә алмаганнар өчен дә чыгыш ясарга. Елена әйткәнчә: “Дөнья дерелдәп куярлык булсын!” Бер сүз белән әйткәндә — нык торыгыз! Ә медальләр, һичшиксез, булачак...

Александр АЛЁШИН




Иван АНЧУКОВ








Александр ШМИДТ



Виктор ФЁДОРОВ



Сергей ЕРМИЛОВ






Быел олимпия хәрәкәте башланып китүгә 120 ел тулды. Шул вакыттан бирле ярышлар программасына гадәти булмаган яңа төрләр өстәлде. Мәсәлән, Париждагы 1900 елгы Олимпиадада спортчылар 200 метрлы арада йөзүне каршылыклар аша үттеләр. Аларга, Сена елгасында колга башына менәргә, аннан кире суга төшеп, көймәгә менеп утырырга һәм яңадан елгага чумып, көймә астыннан йөзеп үтәргә туры килгән... Йомшак итеп әйткәндә, мондый сәер йөзү ярышы әллә ни популярлык казана алмый, шуңа күрә аны башка вакытта Ярышлар прогрммасына кертмәгәннәр.



Париждагы Олимпиадада игътибарга лаек программаның тагын берсе — күгәрченнәр ату ярышы. Бельгия кешесе Леон де Лунден, 21 күгәрченнең гомерен кисеп, чемпион булган. Ярышлар вакытында 300 күгәрчен җан тәслим кылган. Алдагы Олимпиадаларда мәрхәмәтле атышка күчкәннәр: очып баручы тәлинкәләрне кырганнар.


Хәзерге вакытта аркан тарту — күңелле уеннарның берсе, ә кайчандыр ул җитди спорт төре булып саналган. Хәтта 1900 елдан алып 1920 елга кадәр Олимпиада уеннары программасына кертелгән. Уеннарда аны тартып кына чикләнмәгәннәр, аның буенча үрмәләп өскә менгәннәр. Бу очракта инде менеп җитү тизлеге дә һәм осталык техникасы да исәпкә алынган. Соңгы тапкыр арканны җегәрләүчеләр 1932 елда көч сынашканнар. Шунысы кызык: хәзерге вакытта да бу төр ярышларын яңадан Олимпия программасына кертү тарафдарлары табылып тора.


Хәзерге көннәрдә дә яңа төр спорт уеннары Олимпиадада күренер дип фаразлана. Мәсәлән, спортчылар арасында менә мондый уеннар килеп чыгу мөмкинлеге җитди уйланыла... компьютер уеннары. Ә нәрсә? Шул ук атучылар — куышлы, тотышлы, качышлы, ләкин виртуальдә...





Югары таләпләр









Безнең таләпләргә туры киләсез!

4
5

Миргалим ХАРИСОВ

БАРГАНСЫҢ ИКӘН, КЕР...

Идел буе һәм Урал яны композиторлары фестивале 1985 елда Мари Республикасы башкаласы Йошкар-Олада узды. Тел-теш тидерерлек булмады, әйбәт оештырылган иде. Якташлары – күренекле композитор Андрей Эшпай да килгән иде. Таныштым. Икенче көнне иртән кунакханәдә очрашып, интервью алдым. "Ангара" балеты, башка күп әсәрләр авторының музыка сәнгатенең бүгенге торышы турындагы фикерләре белән газета укучыларын да таныштырдым. Ә берсе белән ул вакытта таныштырып булмады...

Фәлән көнне фәлән сәгатьтә (тарих өчен аларның төгәл вакыты әһәмиятле түгел) алты республика композиторлары берлекләре рәисләрен партиянең Мари өлкә комитеты беренче секретаре Прокопьев кабул итә икән, дигән хәбәр ишеттем. Белештем – дөрес. Килдем. Ул чакта әйткәнчә, обкомга, мендем тиешле катка.

Безнең обком кебек үк булмаса да, аларныкы да обком инде: тикшерүчеләре, Беренче ишеге төбендә торучылары бар. "Сез кем, нишләп йөрисез, сез исемлектә юк, монда фәлән кешегә генә сувенир-бүләк әзерләнгән", – диләр миңа кабул итү бүлмәсе янәшәсендәгеләр.


"Миңа сувенир-фәлән кирәкми. Татарстанның иң өлкән, иң күп тиражлы, марилар да, чуашлар да укый торган газетасы хәбәрчесе мин. Сезнең республикагызны, кунакчыллыгызны яктыртасым килә, махсус шуның өчен килдем, мондый очрашу турында язмасам, минем монда килүемнең ни мәгънәсе бар?" – дигәнрәк сүзләр белән юмаладым тегеләрне.

Керттеләр Беренче бүлмәсенә. Билгеле инде, сөйләшү: әйбәт мондый очрашу-чаралар, алар дуслыкны ныгыта, мәдәниятләребезне баетышуга ярдәм итә, дигәнрәк формада үтте.

Очрашу соңында Беренче секретарь композиторлар башлыкларына сувенир-бүләкләр – Мари Республикасы турында альбом-китаплар өләшә башлады. Алты бүләкне бирде дә... миңа карап аптырап калды.

Шунда мин:

– Һич тә борчылмагыз, мин монда исемлексез генә кергән кеше, Казаннан килгән газета хәбәрчесе, гафу итегез, – дидем.



Виктор ИГНАТЬЕВ, «Чаян» № 9, 1976

– Сакал-мыекларыгызны кырып килегез – иртәгә юниорлар өчен уйныйбыз!

Буйга бәләкәйрәк, әмма таза гәүдәле Беренче безнекеләр кебек үзен әллә кемгә куя торганнардан түгел иде – һичьюгы миңа шулай тоелды – ярдәмчесенә ниндидер ым какты да, тегесе, каяндыр табып, әлеге альбом-китаплар төргәген кертте. Беренче, гафу үтенеп, аны миңа бирде.

Ә Казанга кайткач...

Әлеге кабул итүдә Татарстан өлкә комитеты мәдәният бүлеге инструкторы Л. Алексеева катнашкан иде. Кайткач, күрәсең, бу хәл турында бүлек мөдире Дания Хөсәеновна Зариповага җиткергәндер. Анысы нәрсә дигәндер, белмим, тик Алексеева миңа эшкә шалтырата:

– Аңладыңмы хатаңны? – ди.

– Нинди хатаны? – дим.

– Йошкар-Оладагы...

Йомшак сөйләшә. Дания Хөсәеновна мәдәният мәсьәләләрендә дә, характеры белән дә йомшак кеше иде, каты бәрелмә, дип кисәткәндер, мөгаен.

– Мин үкенерлек бер хата да эшләмәдем, газетабыз заданиесен үтәдем. Шунда да кермәгәч, мин анда нигә дип барырга тиеш идем соң?! – дидем.

Башка сүз булмады.

Моны искә алуымның сәбәбе шул: кайбер журналистлар редакция заданиесе белән баралар да, фәлән завод, фәлән предприятие башлыгының ярдәмчесе яки бер куштаны кертмәде, дип, мәгълуматсыз-нисез кайталар.

Баргансың икән, ничек итсәң ит, кер, үзеңнекен булдыр.

Журналист шундый булырга тиеш түгелмени?!

Камил КӘРИМОВ

КӨН ҺӘМ АНЫҢ ТӘРТИБЕ

Беркетмә. 1986 ел, 7 май, 15.00 сәгъ.

Миңнуллин (алга таба Т. Мин.). Җәмәгать, бүгенге идарә утырышына өч мөһим мәсьәлә куелды. Аларны көн тәртибе дисәк тә була. Беренчесе – ике идарә арасында эшләнгән эшләр. Икенчесе – Дәүләт премиясенә тәкъдим итү өчен кандидатлар билгеләү. Өченчесе – гадәттәгечә, кызыграгы – төрлеләр. Кемдә нинди тәкъдимнәр бар?

Ә. ГАФФАР. Икенче көн тәртибеннән башлыйк.

Т. МИН. Син, Әхәт, кирегә сукалап утырмасаң, Гаффар булмассың шул. Көн тәртибен тәртипне, бозмыйча гына башлыйк. Җәмәгать, Тукай көннәрендә күп кенә язучыларыбыз төрле шәһәрләрдә укучылар белән очрашулар үткәреп кайттылар, аларны тыңласак, идарә эше мулрак булып күренер. Әйдә, Мөхәммәт, синнән башлыйк.

М. МӘҺДИЕВ. Без бер иптәш белән... кем әле, теге, бар бит әле... Шагыйрьме, драматургмы... Мөсәгыйть, кем әле ул теге?!.

М. ХӘБИБУЛЛИН. Мансур Зиннуровны әйтәсеңме?

М. МӘҺДИЕВ. Әйе. Без әнә шул иптәш белән Магнитогорскига килеп төшкәч, күрсәгез... егерме отборный кызны сайлап төзеп куйганнар... Ансамбль икән. Мәхмүт Хөсәенне көткәннәр. Мин пока Хөсәен түгел шул әле, дигәч, бик кәефләре төште. Кичә вакытында гел М. Хөсәен шигырьләре генә яңгырап торды. Миңа, "Чебиләр" шигырен сөйлә, дип бәйләнделәр. Икенче юлы барганда әбизәтелне өйрәнергә туры килер. Китәр алдыннан М. Хөсәенгә тиешле Мактау кәгазен төзәтеп миңа бирделәр.

М. МАЛИКОВА. Барган җирдә редакцияләр өчен материал алып кайттыңмы соң?

М. МӘҺДИЕВ. Менә шул инде бөтен материал. Мәхмүт Хөсәен килсә, бәлки, балын-маен-итен-карабодаен һәм башка материалларны кызганмаслар иде. Ә мин буш кайттым.

РАЗИЛ В. Свердлауга барып төшсәм... анда Мәһдиевне көткәннәр икән.

М. МӘҺДИЕВ. И, белгән булсам!

РАЗИЛ В. Бөтен афишаларда Мәһди исеме, шуңа күрә миңа артык игътибар булмады. Юкса 1200 кешелек зал шыгрым тулган иде.

Ә. ГАФФАР. Син, Разил, Җәлил премиясен алдың да котылдың. Иптәшләр, икенче көн тәртибенә күчик инде!

Р. МИҢНУЛЛИН. Ашыктырма, Әхәт.

Г. АХУНОВ. Миңа сүз биргәндә генә регламентны кысасыз. Мин Саратовка барып "Волга" журналының 20 еллыгын үткәреп кайттым. 20 ел эчендә анда бик күп татар язучыларының әсәрләре йөзде... ие, дөнья күрде. Мәсәлән, минем Шаһиданең...

ҮЗЕМ. Покороче, Гариф абый.

Г. АХУНОВ. Короче шул, Кәримов, син менә "Идел" альманахында редактор булып утырган буласың инде, ә "Волга" "Идел" ише генә түгел ул сиңа!

Р. КӘРАМИ. Гариф абый, Төмән өлкәсенең Лангепас районында урман да урман гына, кругом сазлык. Әдәби пост ачып кайттык, Әдәби постның вәкиле итеп Илдар Юзеевне билгеләдек.

И. ЮЗЕЕВ. Туктагыз әле, минем унике җәмәгать эшем бар бит инде... кайсына гына өлгерим?! Әнә, Рөстәм Мингалимовны куегыз.

Р. МИНГАЛИМОВ. Минем радикулит бит, агайнеләр, сазлыкта йөрергә ярамый. Әнә, Әхсән Баян ризалашсын.

Г. АХУНОВ. Әйе шул, мин риза!

Т. МИН. Җәмәгать...

Ә. ГАФФАР. Икенче көн тәртибенә күчәбез, брат!

Т. МИН. Җәмәгать...

Ә. ГАФФАР. Премияне бүләбез...

Т. МИН. Җәмәгать, тәнәфес...

Язучыларның "Тынгысыз каләм" дигән дивар гәзитеннән. 1989 ел.

Вадим МАЛЯКИН, «Чаян» № 3, 1976







Дамир ФӘЛАХОВ

Тагын бер гомер

– Улым, хәлем бик авыраеп китте, үләм, ахрысы…

– Әнкәй, син алай шаяртма! Бүген әле дүртесе генә, ә унысында сиңа пенсия китерергә тиешләр… Азрак гына түз инде…

– Карәле, улым, сулыш алу кыенайды…

– Синең шул булыр инде! Гел үзең турында гына уйлыйсың! Мине өченче хатыныма ботарларга калдырмакчы буласыңмыни?

– Аһ, күз алларым караңгыланды…

– Син миннән бик җиңел генә котылмакчы буласың бугай! Син миңа ана түгелмени? Ә оныкларыңны кем аякка бастырыр?

– Улым, әптиккә даруга барып килмәссең микән…

– Барырмын… Түлке менә бакчаны үземә утарга туры киләчәк инде…

Әй, улым, тыныч кына үләргә дә бирмисең инде… Йөз иллегә кадәр яшәргә язгандыр, күрәсең… Ярый инде, үзем барып килермен..

Әллә кайчан шулай диләр аны! Үләм, имеш… Безне әле алда тагын бер гомер көтә!

Александр ШМИДТ



Сергей АНДРИАНОВ



ШИГЪРИ ДУЭЛЬ

Рашат Низами: Зәңгәр бозлар. Ак диңгездә ага…
Без агабыз икән кай таба?

Алмаз Хәмзин: Ни кызганыч!!. Тыз-быз тормыш-гел боз…
“Титаник” чоңгылына каба.

Р. Н.: Сорылыкны тар-мар итәр өчен
Мин чакырам шигырь гаскәрен!

А. Х.: Мин дә шулай шапырынып идем,
Юк шул язган юньле әсәрем.

Р. Н.: Язгы сулар белән бергә
Агып китте сөю хатларым.

А. Х.: Күзең җиткәч, кат-кат укыр
Үрти-үрти шуны хатының.

Р. Н.: Кешеләрне, илне тәнкыйтьлибез,
Кырыс гадәт бездә бар шулай.

А. Х.: Ник берәү имзасын куйсын язгач,
Юк шул бездә кыю, юк — Тукай!

Р. Н.: Болын яме — чәчәк белән,
Мендәр яме — кыз белән.

А. Х.: Син өйрәтмә, Рашат дустым,
Нәрсә ямьле — мин беләм!



ПОКЕМОН ЗӘХМӘТЕ

Ринат АБЗАЛОВ



Александр АЛЁШИН





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

— Әйтегез әле, шәһәрдә кайчан юлларны төзәтәләр? Автобусларда чыдап булмаслык селкетә.

— Ә сез тотынып йөрегез.

• • •

Күз алдына китереп булырлык түгел, илдә төпле һәм намуслы 8 губернатор таба алмаганда, ничек инде 11 футболчы табасың?

• • •

Миңа ОБЖ дәресендә аю очрагач нишләргә кирәген өйрәттеләр, ә менә хезмәт хакың булмаганда нишләргә икәнен аңлатмадылар.

• • •

“Саумысыз, мин сезнең номерыгызны алырга теләр идем”. Менә шундый ягымлы гаишник туры килде миңа...

• • •

— Әгәр дә сезнең миллиард сум акчагыз булса нишләр идегез?

— Әле генә бар, хәзер инде юк дип борчылган булыр идем.

• • •

Хатыны – иренә:

— Берничек тә аңлый алмыйм шушы төп һәм ят салымнарның аерымлыкларын.

— Ничегрәк итеп аңлатыйм? Ул менә болайрак: син бит башта минем бөтен хезмәт хакымны тиенenә хәтле сыпырып аласың, ә төнлә, мин йоклаганда, кесәмне актарасың.

• • •

— Нишләп сез үзегезгә бик сәер бухгалтер алдыгыз — пеләш, аксак, колаклары алагаем?

— Шундый күркәм сыйфатлары булганы өчен!

• • •

— Доктор, минем касыкка эчтән нәрсәдер кадый.

— Ул мәрхәмәтлеллегең, ышанучанлыгың һәм ярдәмчелегең.

— Нинди мәгънәдә?

— Ә алар синнән шулай чыгалар. Урыс әйтмешли — боком выходят...





Виталий ФЕОКТИСТОВ



«Чаян» остаханәсе зур югалту кичерә. **Виталий ФЕОКТИСТОВ** арабыздан китте. Рәссам, карикатурачы, полиграфия остасы, шагыйрь, хикәяче. Белеме буенча архитектор, күңеле белән – чаянчы…

Аның кырык елдан артык гомере "Чаян" белән бәйләнгән иде. Виталий Феоктистовның кабатланмас график стиле, үткен темалары һәм бер күрүдә танылып торган персонажлары белән аерылып торган рәсемнәре берничә буын укучыларын шатландырып килде. Ул әсәрләр һәм, гомумән, "Феоктистов" фамилиясе журналның билгесенә әверелде.

Кайгы һич көтмәгәндә килеп төште. Шат күңелле, үткер акыллы, киң белемле һәм тормыш сөючән Виталий әле кичә генә безнең арабызда иде. Үзенә генә хас җанга ятышлы йомшак тавышы белән киләчәк саннарны планлаштыруда катнаша, киләчәк белән бәйле фикерләре белән бүлешә иде. Кызганычка каршы, кырыс язмыш бөтенесен үзенчә хәл итте. Якын дустыбызны соңгы юлга озаттык, әмма аның "Чаян" тарихына язылган иҗаты һәм исеме калды. Сирәк талант иясе, искиткеч яхшы күңелле Виталий дустыбыз турында җылы истәлек безнең йөрәкләрдән мәңге җуелмас.

«ЧАЯН»ЧЫЛАР.

СҮЗ ИЯРӘ СҮЗ

- Ул күктә очып йөрмәде – ышанычлы итеп җирдә басып торды. Аңа куенында йөрткән зур таш ярдәм итте.
- Капчыкта без йөртүгә караганда, таш йөртү хәерлерәк – ышанычлырак ята!
- Хатын-кызның бер минутлык йомшаклыгыннан файдаланыр өчен ир кешегә күпме вакыт һәм көч сарыф итәргә кирәк!
- Гел эшкә бирелеп кенә яшәсәң, гомерлеккә карт кыз булып калуың бик мөмкин.











АДАШКАН ФИКЕРЛӘР

● Хәзерге заман драмасы европача: ул хатынына аның сөяркәсе белән хыянәт итә.

● Караңгылык куерган саен, бәйрәм салютлары ешрак оештырыла.

● Минә, ниһаять, миңа бәхет елмайды!.. Ләкин ул бары тик көлгән булып чыкты!

● Иртәгәге көнгә шикләнеп карасак та, якты киләчәккә һичсүзсез ышанабыз.



Виктор БОГОРАД



Эльвира ДЫШАЕВА





КРИЗИСКА КАРШЫ — “ЧАЯН”!

Кадерле Чаян! Кризис дигән ләгънәт тәки үзенекен итте бит, еллык планнарыма үз өлешен кертте дә куйды. Бер җирдә дә эшләмәгәнлектән, бераз акчаны янда калдыру нияте белән быелгы газета-журналларга язылмаска булдым. Ләкин, күптән түгел “МАП” агентлыгы “Укырга һәм язарга яратам!” дигән конкурс игълан итте. Мин дә үземне тыеп кала алмыйча яраткан басмаларым турында язарга булдым.


Яратам укырга, язарга,
Күп белергә яратам.
Дусларыма бүләк итеп
Журналлар мин яздырам.

Укысыннар төрләләрен –
“Футбол”ны, “Аптечка”ны.
Кызык басмалар иллә күп,
Ә мин укыйм “Чаян”ны!

Призлы урын ала алмасам да, минем шигыремне бәяләделәр. Юкка гына шигыремдә дә “Чаян”ны беренчеләрдән булып шигырь юлларына салмадым, һич кенә дә аерыла алмыйм. Почтага барып журналга язылуны озайттым. Ә дус кызымның туган көненә ярты елга язылу бүләк иттем. Менә шулай итеп, “Чаян”га булган ихтирам һәм ярату сузылган кризиска караганда көчлерәк булып чыкты.

С. КОНЯШОВА

п. САНБОЛИ,
ХАБАРОВСКИЙ КРАЕ.



ОНЫТЫЛГАН ЧИБӘРКӘЙ

Чаян дус! Яңа елны ничек каршы алсаң, алдагы елың нәкъ шулай дәвам итәчәк дигән әйтем бар. Күрәсең, ярты еллап бизәгән һәм онытылган чыршыга караганда, безнең йорт халкы бик шәп каршы алган Яңа елны. Олимпийск бистәсе, Технический урамы турында сүз бара. Бу инде беренче тапкыр гына түгел, узган ел чыршысы 9 нчы майга кадәр бизәп торды.

Кызык, онытылган урман чибәркәе быел 1 сентябрьгә яисә халык бердәмлеге бәйрәме, һич булмаса киләсе Яңа елга кадәр торыр микән?

Ф. ШӘРИФУЛЛИН

ПИТРӘЧ

ДУҢГЫЗЛЫК

Хөрмәтле редакция! Кармак салып утыручылар өчен балыклы урын табу – ул үзе бер уңыш бит. Балыкчыга балыклы урын табып кармак салып ләззәтләнеп утыру — бик зур уңыш китерәчәк дип саныйм мин үзем. Минем өчен шундый урын Яшел Үзән районындагы Секерка елгасы булды. Ул урынга күптән күз салып куйсам да, быел гына бара алдым.

Тик көтелмәгән хәлдән тынсыз калдым. Элеккеге матур елгадан җилләр искән. Протопоповка авылы читендә – елга буенда ук дуңгыз фермасы барлыкка килгән.

Күпме тырышсам да, кармак салып утыру бәхетенә ирешә алмадым. Фермадан килгән сасы ис ләззәтләнеп балык тоту теләген калдырмады. Күрәсең, фермадагы бөтен шакшы әлеге елгага агып төшә. Балыгы да элеккеге кебек түгел. Кызганыч, балык тотардай шәп урыннар елдан-ел кими бара... Ә монда дуңгызлык эшләп куйганнар.

КАЗАН

Р. АРСЛАНОВ

ЮЕШ ЭШ

Чаян дус! Эшмәкәрлек ачу авыр эш түгел хәзер. Ә менә ябарга уйласаң, ай-һай, җиңеллән түгел икән! Гайдар урамының 3 нче йортында яшәүчеләр моны бик яхшы белә. Берничә ай инде тәрәзә каршындагы иске гараждагы автоюгычны ябарга азапланалар.

Бик күп шикаятьләр язгач, эш бераз кузгалды бугай. Автоюгыч белән прокуратура шөгыльләнә башлады. Гаражны яптылар, хуҗадан эш туктатылды дигән гарантияле хат алдылар. Тик бу туктатылу язма рәвештә генә калды, ахрысы. Халык әйтүе буенча монда эш гөрли: утлар яна, машиналар юыла...

Хәзер исә, автоюгычка каршы бер төркем халык судка барырга исәпли. Бәлкем, суд әлеге “юеш эшкә” нокта куяр...

Д. ЯРУЛЛИН

ЧАЛЛЫ

Эрнест ДЫШАЕВ







Валерий **АНТОНОВ**

Дошманга үч итеп

Күптән түгел куллары махсус сыекчага буялган чираттагы губернаторны тотканнар. Ә мин болай уйлыйм: коррупция белән көрәшү өчен кәгазь акчаларны гына билгеләү җитми. Монда заводлар, нефть скважиналары, газүткәргечләр, күмер шахталары, банклар, коттеджлар, яхта һәм самолётлар, кыйммәтле бүләкләр, сөяркәләрне дә кертергә кирәк...

Тик бу зур мәсьәләне чишәргә бөтен халык тотынырга тиеш. Ул чагында берьюлы кризисны да җиңеп ташлаячакбыз. Ничек, дисезме? Кичекмәстән илдә зур масштабларда махсус сыекча җитештерүне оештырырга кирәк. Дистәләгән елларга җитәрлек итеп. Планны мең процентка арттырып үтәп.

Шулай итсәк, илдә эш кайнап торачак, ял итәргә дә вакыт булмаячак. Дошманнар көнләшеп үләчәк!



Галия **МӘУЛЕТОВА**

Розапа һәм Вәли Вәлиевич

Белгәнебезчә, бер пенсиягә генә яшәп булмый, шуңа күрә Розапа җыештыручы булып эшкә урнашты. Конторада бүлмәләр күп, барысында да эндәшми-тынмый гына кешеләр компьютерларына карап утыралар, ә кичен көчкә аякларын өстерәп, өйләренә кайтып китәләр. Бер сүз белән генә, Розапа әйтмешли: "Ялкаулар! Ә артларыннан чүп-чар һәм тузанның чуты юк! Җыештырып бетерерлек түгел!"

Бервакыт аны директорга чакырттылар.

— Менә нәрсә, апа, гариза язгыз әле! — дип ачулы рәвештә сүзен башлады начальник.

— Нинди гариза? — чүт артына утырмады шулчак җыештыручы.

— Эшегездән азат итүне сорап!

— Ничек инде ул шулай кисәк кенә? — дип, гаҗәпкә калыбрак, әйтеп куйды Розапа.

— Минем синең урынга башка кешем бар! — диде директор.

— Минем урынгамы? — дип каушабрак сүзен башлады да Розапа, тиз генә хәлгә килеп, һөҗүмгә күчте. — Нинди кеше ул?! Менә хәзер мин Вәли Вәлиевичкә шалтыратам, ул сезгә шундый кандидатура күрсәтер, үзегезнең кәнәфиегездән очып төшкәнегезне сизми дә калырсыз!

— Кайсы... нинди Вәли Вә... — дип, тотлыга-тотлыга кәнәфиеннән күтәрелде директор.

"Әллә үзенә үк шалтыратырга җыенамы?.. Бу картлардан бөтенесен көтәргә була... — шундый шомлы уйлар чагылып китте җитәкче башында. — Тиздән сайлаулар... Шул гына җитмәгән иде..."

— Шуңа булмый! — дип, бик хәйләкәр генә күзен җыерыбрак, сүзен дәвам итте Розапа. — Ул сезнең барыгызны да түбә башына утыртачак!

— Ул бит сине тыңлау түгел, күрергә дә теләмәячәк, — диде директор, кулын селтәп. — Аның бүтән эше юк мәллә...

— Ә мине ул тыңлаячак! — дип ышанычлы итеп үзенекен дәвам итте җыештыручы, түшәмгә бармагы белән күрсәтеп. — Вәли Вәлиевич пенсионерларны хөрмәт итә. Әнә күптән түгел бер идарә компаниясенең җулигын эшеннән алды. Кем алдыртты дисеңме? Минем кебек бер әби!

— Сез чамалабрак сөйләшегез, — диде директор, шикләнебрәк түшәмгә карады һәм пошынып әйтте.

— Ә миңа нәрсәдән куркырга! — дип кызып китте Розапа. — Мин чит кеше урынына кызыкмыйм һәм үземнекен дә бирмим. Шуны белеп торыгыз!

— Барыгыз, бар, китегез... — нишләргә белми мыгырдап куйды директор. — Половой эшегездә булыгыз...

Директорның соңгы сүзен Розапа бик аңлап бетермәсә дә, шуңа төшенде — дошман җиңелде. Ул аңа тантаналы төстә чүпрәк ураган югыч таягы белән кизәнеп, кабинеттан чыкты.


— Сайлаулардан соң бирермен әле мин сиңа кирәгеңне! — дигән сүзләрен Розапа, билгеле, ишетми калды.

Розапаның контoрадан чыгуын Вәли Вәлиевич Шәпиев инде күптән көтеп тора иде. Ул хәрби пенсионер һәм аның күршесе. Кайчагында ул Розапаны эшеннән кайтканын көткәләп торгалый. Һәм алар, бергәләп, районның ветераннар җәмгыятенә җыелышка йөриләр. Владимир Владимирович шул җәмгыятьнең рәисе...


Илдар НӘФИЕВ



Илдус АЗИМОВ



Ринат БӘШИРОВ





Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

Исегездә тотыгыз: тормышта барысы да чагыштырмача. Әгәр дә сезне бер җирдән ачуланып кусалар, икенче төштә зарыгып көтәләр!

• • •

Кичә паркта ял итеп йөргән егет белән бер кызны күрдем, ә бүген шул ук егет инде икенчесе белән йөри. Кызлар егетләрен бигрәк тиз алыштыралар инде.

• • •

Һава торышын билгеләүче үзәк, йөрәк авырулы кешеләрне һава басымы күтәрелү турында гына түгел, ЖКХ тарифлары артуы турындагы белешмәләрне дә әйтеп кисәтеп торачак.

• • •

Нигә Рәсәй җыелма командасы футболчыларын таратырга, алар болай да инде төрле яктан "таркау".

• • •

Ертылып беткән джинсы кигән кызны күрәм — аңлыйм, яхшы хуҗабикә булачак, киемнәрне саклык белән кия, димәк, менә дигән хатын. Мондый кеше тунын егерме еллап киячәк.

• • •

— Әби, ә сезнең Советлар Союзында яһүд радиотапшырулары бар иде-ме?
— Әйе, "Пионерская зорька".
— Ә нишләп ул яһүднеке?
— Чөнки ул 7дә 40 та башлана иде. Урыс әйтмешли: "Семь сорок".

• • •

— Үскәч син кем булырга телисең?
— Доктор.
— М-м-м... Мин андый билгеләргә укыган докторга бармас идем.
— Мин бит "докторга" дип әйттем, "ветеринарга" түгел!

• • •

Без яраткан хатын-кызларыбыз янына тәрәзәләрдән керүне оныттык!


• • •

"Спас" каналында иртәге өчен һава торышын күрсәтәләр! Кешеләр Алланың планнарын каян белсеннәр инде?

Илдар НӘФИЕВ



Александр КОСМЫЛИН



Евгений ОБУХОВ

ЭТИКЕТКА

Генераль директор җыелганнарга алҗыган караш ташлады һәм мескенләнеп әйтеп куйды:

– Тик миңа һәйкәл куярга кирәкми!

– Нинди һәйкәл? – дип гаҗәпсенде халык.

– Нәрсә, минем теге дөньяга китүемне телисезме? – диде директор тын гына. – Пычаксыз суясыз бит! – Аның тавышы көчәйгәннән-көчәя барды. Ниһаять, ул йодрыгы белән өстәлдәге кәгазьләр өеменә китереп тондырды. – Бу нәрсә, дип сорыйм мин сездән?!

Маркетинг һәм реклама буенча урынбасар күтәрелде. Нәчәлникнең усал карашыннан хәле китеп, ул агарынып киткән куллары белән өстәл читенә тотынды:

– Бу – безнең продукция өчен этикеткалар...

– Ә, этикеткалар дисеңме?! Йә, вак шрифт белән язылган текстны укы әле.

– Вак шрифтмы? Әһә, димәк, монда язылган: “Состав... табигый үсемлек майлары... май эквиваленты... соя лецитины... Е476... көпшәкләткеч, йомшарткыч – натрий гидрокарбонаты... алыштыргыч... антиокислитель...”

– Әһә, укыдың бит! Димәк, сатып алучы да укыячак! Нәрсә, анда сезнең ваграк шрифт табылмадымыни?

– Менә, карагыз, ваграк вариантлары да бар...

– Тә-әк, монысы инде шәбрәк... Тагын да ваграгы бармы? Ягез, монысын кем укый ала?

Чиратлашып, барысы да укырга тырышып карады. Тик берәү дә продуктның исеменнән башка берни дә күрә алмады.


Маладис! – диде директор, урынбасарга карап. – Монысы ярый! Этикетканы бастырып чыгару хәстәрен күрә башлагыз. Тагын менә нәрсә: текстны караңгырак фон өстенә куярга тырышыгыз. Йә берәр җүләре кибеткә прожектор белән микроскоп алып килер дә продуктның нилардән торганын укып чыгар! Кем белә бит...

Җәй айлары...

Сергей КОКАРЕВ



Илдус АЗИМОВ



КӨТЕЛМӘГӘН ХӘЛЛӘР

Кайвакытта су буендагы җәйге яллар күпләргә көтелмәгән хәлләр тудыра. Бигрәк тә Кояш астында үзеңне ярамаган эчемлекләр белән кыздырып торсаң. Моңа пляждагы кызынучылар мисалы байтак...

Июль башларында, яшь кенә Эльвира исемле әни кеше үзенең ял көннәрен бер яшьлек баласы һәм сердәше белән Аккош күлендә – ягымлы табигать кочагында үткәрергә була. Үзләре белән ике литр ярымлы шешәле сыра да алалар. Бала күз алдында күбекләнеп торучы эчемлек куллануны итагатьсезлеккә санап, баланы кәгазь көймә йөртеп уйнарга су кырыенда калдыралар. Ә үзләре сыра тәменә бирелеп дөньяларын оныталар. Пластик шешәдәге сыраны төбенә хәтле чөмергәннән соң, җырлап та алалар, аннан эссе кояш астында йоклап та китәләр. Бер сәгатьтән әни кеше уянып китә, һәм пляж буйлап үкереп йөри башлый: "Кая минем балам?!" Бәхеткә, килеп җиткән коткаручылар баланы табып алалар. Ул тыныч кына үзенең төзелеп бетмәгән ком причалы янында йоклап ята икән...

Ә бит бу хәл бик кызганыч булып бетәргә мөмкин иде. Быелгы елның бәхетсезлекләр статистикасы шуны күрсәтә: кайберәүләргә әлеге коену соңгысы булган. Янәшәдә өлкәннәрнең булмавы шундый фаҗига китереп тудырган.

Югары Ослан районының Макарьев монастыре янындагы җәйге лагерь балалары өчен дә судагы ял бик кызганыч булып бетәргә мөмкин иде бит. Коткаручылар вакытында күреп алмаса. Унлап бала, янәшәләреннән үтеп баручы баржалар, пароходлар калдырган дулкын кочагында шаярышып, уйнап коеналар икән. Ник бер өлкән кеше, катерлар, көймәләр буразналап очып йөргән җирдә коенырга ярамый, дип ачулансын... Күрәсең, лагерь җитәкчеләре халык әйткән акыллы фикерләрне телгә дә алмый: "Ходай саклanganны гына саклый!.." Шул сәбәпле, лагерьны япканнар, балаларны өйләренә озатканнар.

Әйе, суда йөзү, коену тәртипләрен күпләр үтәми шул. Кагыйдә бозуның иң таралганы: көймәләрдә һәм катерларда коткару жилетларның булмавы. Бу – исерек килеш балык тотып йөрүчеләр белән бер чамадагы фаҗига. Күп очракларда бер дулкынның китереп бәрүе бөтен жилетсыз компаниянең балыклар ризыгы булып, төпкә китүенә сәбәп була ала. Кызганычка каршы, мондый көтелмәгән хәлләр еш кабатланып тора шул...

Арслан СИБГАТУЛЛИН

Рушан ГАТАУЛЛИН



Хәтер һәм әҗер

Еллар үтә тора, ә булганчык туксанынчы еллар каһарманы Сергей Мавродиның кеше акчасы белән кылган «батырлык»лары кайберәүләргә әлегә кадәр тынгы бирми. Шунысы гаҗәп: андыйлар янына күз ачып йомганчы Леня Голубковның «партнёр»ларына ышанучы беркатлы халык җыела тора. «МММ» авыруы бик яшәүчән булып чыкты һәм берничә дә карамастан, Россиядә пирамида төзү өянәге даими рәвештә кабатланып тора.

Бу кизү республикабызны да читләтеп үтмәде. Соңгы өч ел «кредит-кулланучылар кооперативы» дигән маска астында яшеренгән яңа финанс пирамидаларының пәйда булуы белән билгеләнде. Полициягә инде ун меңнән артык(!) мошенниклар тарафыннан алданган кеше мөрәҗәгать итте.

Мисал өчен, Лениногорск шәһәрендәге «мавроди» өч дистә «инвестор»дан сәмән җыярга өлгергән. Пирамида масштабы өчен кредит-кулланучылар директорының керемнәре әллә ни зур да булмагандыр – бары тик биш миллион сум. Ләкин «фирма»ның бөлүе турында бөтен акча кертүчеләренең белмәве мөмкин бит, ә җиңел табыш артыннан куучыларның саны, бәлки, һаман артып барадыр...

Менә Чаллыдан Елена Филатова киңрәк колач белән эшләгән. Аның кредит кооперативы үз сафларында мең ярымнан артык кеше туплап, аларның кесәләрәннән 140 миллион сум тартып чыгара алган. Чаллыдагы бөтен пирамида корбаннарының тарихлары нәкъ бертөрле. Башта 30 процент табышка өмет баглап, зур булмаган сумма керткәннәр. Керем алырга вакыт җиткәч, аларга акчаны 120 процентка арттыру вәгъдәсе белән кертем тотуның срогын озайту турында тагын да кызыклырак тәкъдим ясалган. Мондый татлы калҗадан баш тарту авыр, әлбәттә. Тик менә Филатова җыелган акчаларны оста гына үз кесәсенә салып барган.

Республика мәркәзе дә үзенең пирамида төзү осталарын үстерде. Мәсәлән, «Кваттро» холдингы хуҗасы Ратмир Заһитовны өч ел буе эзләгәннәр. Аның шашкын финанс эшчәнлегенең нәтиҗәсен тикшерү органнары йөз миллион сумнан артык бәяли. Бу эшчәнлекне суд күпмегә бәяләр, анысын инде вакыт күрсәтер.

Барча «төзүче»ләр дә хокук саклау органнары кулларына эләктеләр, әлбәттә. Мондый «бизнес»ның башкача тәмамлануы мөмкин дә түгел. Акча артыннан куып, Мавроди шәкертләре остазларының «Форбс» исемлегенә түгел, ә төрмә камерасына эләккәнлеген онытканнар, күрәсең. Тир-кан түгеп җыйган акчаларын үз теләкләре белән шикле контораларга илтеп тапшырган бәндәләрнең дә акылхәтерен камил дип булмый...

Людмила САФИУЛЛИНА



Эрнест ДЫШАЕВ

Ринат МӘННАН

ТУФАН АБЫЙНЫ САГЫНЫП...

Әдәпсез инсаннар күпме?
Кызганычка, аз түгел!
Бер китап тәкъдим итәм мин,
Күз алдында торсын гел.

Көн дә аны алып укы,
Яхшырырга теләсәң.
Файдасын бик тиз күрерсең,
Була гына күр исән.

Ятласаң, тагын да әйбәт.
Беркем дә килмәс каршы...
Туфан Миңнуллин әсәре —
“Мин — хороший, син — яхшы!”

НИГӘ?..

Мәскәү радиосы сөйли:
Имеш, сыер сөтенә
Кушалар, ди, пальма мае,
Акбур, соя, гипс... Менә!

Сыер сөте болай да тәмле,
Нигә аны бозалар?
Сыердан да оялмыйлар,
Кая бара дөньялар?..

ИР вә ХАТЫН...


Эрнест ДЫШАЕВ



Николай ВОРОНЦОВ



Игорь КИЙКО



Валерий ТАРАСЕНКО



Владимир ИЖБОЛДИН



ЧУАР ПРЕССА

ЕЛМАЮЫҢ БЕЛӘН БҮЛЕШ

Америкалылар бер-берсенә кирәксә дә, кирәкмәсә дә елмаялар. Блогер Бенджамин Беннет дүртәр сәгать видеокамера каршында тиле кеше кебек елмаеп утырган. Ул барлыгы 37 көн елмайган. Иң шаккаттырганы: аның роликларын 3 миллион кеше караган. Аның сәбәпсез елмаюы мәгънәсез ситкомнарга караганда, күпкә кызыграк булып чыккан, күрәсең.

УРМАНГА – АРТЫҢ БЕЛӘН

Австралияле Нил Джордан – йорт хайваннарын кыргый ерткычлар һөҗүменнән саклауның гадәти булмаган ысулының авторы. Ул сыерларның арт якларына күзләр ясарга тәкъдим иткән. "Ерткыч, үзен күргәннәрен сизгәч, һөҗүм итмәячәк", – ди Нил. Мондый ысулны Индиядә урман кисүчеләр куллана икән. Алар башларының арткы якларына маска киеп ач юлбарыслар һөҗүменнән саклананалар.

НЮ ҺӘМ ПРОГРАММА!

Британия телеканалында яңа танышу программасы эшли башлаган. Ялгыз ирләр һәм хатыннар алты кандидаттан үзләренә партнер сайлап алырга тиешләр. Бөтен "фишка" шунда: катнашучылар шәрә. Проектның авторлары, очрашуның барыбер урын-җирдә тәмамлануы белән аңлаталар. Барысы да европалылар кысаларында!

КҮРГӘЗМӘДӘГЕ ХӘЛ

Нюрнбергтагы хәзерге заман сәнгате күргәзмәсенә 91 яшьлек карчык килгән. Аны Дания авангардисты Артур Кепкенең арт-объекты кызыксындырган. Ул аны гадәти башваткыч дип чишкән. Янында "Сүзләр яз" дигән язма эленеп торган. Полиция карчыкны тоткарлаган, чөнки әсәр 100 мең еврога бәяләнгән булган. Аның 60 ы елда эшләнгән булуына карамастан, бәхеткә каршы, коллекционер зыянны көлке хәл итеп кенә кабул иткән.

ЭТЛӘНГӘННӘР

Львов өлкәсендәге бер хәрби частьта этләр присяга кабул иткән. Курсларны узгач, этләр плацта тезелеп басканнар. Кинологлар хәтта присяганың текстын укыганнар. Тәрбияләнүчеләрнең күбесе туп-туры АТО га (антитеррористик операция) юл алганнар. Шулай итеп, Украинага – дан, геройларга – сало!

БӨЕКЛЕКТӘН КӨЛКЕГӘ – БЕР АДЫМ



Дональд ТРАМП

Джоф ГОЛДМАН



Хилари КЛИНТОН

Марк ДЮШЕНЕ

Вячеслав БИБИШЕВ



Алмаз ХӘМЗИН

Виноватлы мәхәббәт

Үтә гомер янып-көеп,
Рәте булмый тормышның.
Мәхәббәтнең баш бетерткеч
Җене бар чукынмышның.

Үтте гомер азып-тузып,
Сынатмадык ни фига!
Хәзер зарланып утырам,
Зарланудан ни файда?

Сөйгән ярлар күп булдылар,
Истә калды бик азы.
Сайланыбрак өйләндем шул –
Килеп капты заразы.

Үтсен гомер, аптырамыйк –
Үткән эшкә – салават.
Мәхәббәттә юл уңмауда
Мин бит үзем виноват.

Үтә гомер, чаба гына
Дулаган айгыр кебек.
Ә мин һаман сине көтәм,
Күктәге Айга менеп.

Вячеслав ШИЛОВ



РОССИЯ СПОРТЧЫЛАРЫ ЗАРЫ

(Бөтендөнья Олимпия Комитеты карары белән, тыелган “допинг”ны күпләп куллану сәбәпле, 2016 елда Бразилиядә узачак җәйге Дөнья олимпиадасында Россиянең җиңел атлетика буенча спортчылары ярышларда катнаша алмый.)

Дөнья олимпиадасы
Спортчыларны җыя,
Бик барасы килә дә бит –
Теге – “допинг” тыя.

Андагы корылмаларга
Күп спортчылар сыя,
Теләкләр зур катнашырга,
Ләкин “допинг” тыя.


Мылтыктан гаять төз атып,
Спортчы очко җыя...
Без дә кимнән куймас идек,
“Шайтан-допинг” тыя...

Африка йөгерешчесе
Ярышта “алтын коя”,
Без дә медаль алыр идек –
Әмма “допинг” тыя...

Тутырырбыз медальләрне
“Капчык”ка күпме сыя...
Дөнья сокланыр, әлегә
Безне тик ВАДА тыя...

Нияз БИШБАЛТА

КҮҢЕЛЛЕ КУНАКЛАР




Чит ил басмаларыннан шаян рәсемнәр


Мирослав БАРТАК (Чехия)



Никола ЛАСТЕЦ (Чехия)




Генри БЮТНЕР (Германия)



Айдир ДОГАН (Төркия)





Ион ПЕТРЕСКУ (Румыния)



Ә МЕНӘ ТАГЫН БЕР МӘЗӘК

• • •

Тараканнарның фатирлардан качуына кесә телефоннары сәбәпче булды, диләр. Озынборыннардан, черкиләрдән арындыра торган яңа буын телефоннары көтәбез.

• • •

Минем кредит буенча берничә ай түләнмәгән, ЖКХга — шулай ук, ялга өч ел чыкканым юк, эштә дә кыскарту көтелә, улым университетта укыган өчен түләү бәясен күтәргәннәр, гомумән — “сез анда чыдагыз”.

• • •

— И җаныем, син шулхәтле матур күренәсең! Ниһаять, хаялыңда йөрткән ирне тапкансың, ахрысы?

— Юк, ташладым...

• • •

Әкият. “Ничек бер мужик ике генералны туйдырган, һәм аның улы армиягә бармаган”.

• • •

— Алё, психбольницамы?

— Әйе.

— Иртәнге сәгать 6 да трубада уйнаучы кеше турында сез нәрсә әйтә аласыз?

— Әлбәттә, аны больницага яткырырга кирәк. Сезнең адрес?

— Хәрби часть, казарма, дневальный.

• • •

Акция! Яңа төзелеш мәйданыннан фатир сатып ал — һәм түләүсезнисез ишегалдындагы һәм подъезддагы чүп-чардан туйганчы рәхәтлән, перфоратор боргычлауларыннан якындагы 10 ел буена ләззәтлән.

• • •

— Сез нәрсә эчәсез?

— Эчемлекнең исеме ике хайван исеменнән тора.

— Конь-як.

— Ә сез күпме эчәсез?

— Икесе берьюлы эчкән хәтле...

• • •


Аптекада:

— Әй, абзый! Ялгышлык киткән — мин сезгә хлористый калий урынына цианистыйны биргәнмен.

— Шуннан нәрсә?

— Нәрсә, нәрсә? Кассага тагын 10 сум өстәп түләгез!

ЮБИЛЯР МӨНБӘРЕ



Вячеслав БИБИШЕВ шаржы

Татарстан Республикасының халык шагыйре, публицист, җәмәгать һәм мәдәният эшлеклесе Ренат Харис (Ренат Мәгъсүм улы Харисов), кырыктан артык поэма, дистәгә якын шигъри цикллар, йөз илледән артык җыр, романслар, кантаталар, ораторияләр авторы. Ул — композитор Мирсәет Яруллин белән берлектә татар милли сәнгатендә оратория жанрына нигез салучы. Аның поэмалары буенча операторлар (“Идегәй”, Р. Гобәйдуллин; “Тукай мәхәббәте”, Резеда Ахиярова) языла, балет (“Йосыф кыйссасы”, Леонид Любовский) куела, телефильмнар (“Камил Якуб”, “Сәйдәш яры”, “Шашкын мәхәббәт”) экранлаштырыла, эфирда радиоспектакльләр (“Сабантуй”, “Гармунчы”, “Чехов базары”, “Бүре күзе”, “Худяков”) яңгырый. Ренат Харис — Бөтендөнья татар конгрессы һәм Фёдор Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивале идеяләре авторы.

Быел, алтынчы майда, күренекле шагыйребезгә 75 яшь тулды. Шул уңайдан, ямьле җәй айларында, үзе төсле җылы, ягымлы шигырьләре аша “Чаян”ыбыз битләре түреннән аңа олы хөрмәтебезне һәм ихтирамыбызны белдерәсебез килә. Әлбәттә, иҗатында зур уңышлар, гаиләсендә иминлек, үзенә саулык-сәламәтлек теләп.

“ИДЕЛ ӨСТЕНДӘ КӨМЕШ АЙ...”

Идел өстендә көмеш Ай
эленгән — китми, бармый,
дымлы комда көмешләнә
акчарлак койган каурый.

Идел суы зәңгәр төнне
ахыргача сеңдергән...
Дулкыннар иренеп кенә
йолдызларны сүндерә.

Мин торам салкын балконда,
ә өйдә җылы-җылы...
Ак түшәктә ауный-ауный,
минем шигырем җылый —

әйтерсең лә гүзәл хатын!
Минем мендәремне кочкан.
Сөюгә багышланганга,
ул җылый куанычтан.

Идел өстендә тулган Ай
эленгән, һаман тора,
балкон тәрәзәсеннән кереп,
шигыремне яктырта.

Идел суы акчарлакның
каурые кебек якты...
Мин дә, бер иркәләним дип,
шигырь янына яттым.

ҮПКӘЛӘМӘСӘНӘ

Гомер ага, ага!
Кайчак юлдан чабам,
кайчак сукмак табам.
Гомер ага, ага...
Үпкәләмәсәнә,
үпкәләмәсәнә —
өзелгән сәдәп тә
әйләнә сәбәпкә.
Үпкәләмәсәнә...
Утлар сүнә, яна!
Бу фани дөньяда
һәр мизгел өр-яңа
утлар сүнә, яна...
Үпкәләмәсәнә,
үпкәләмәсәнә —
ярылган кашык та
хисләрне ташыта.
Үпкәләмәсәнә.

Көннәр килә-китә,
йә бәхетле итә,
йә бәхетсез итә.
Көннәр килә, китә...
Үпкәләмәсәнә,
үпкәләмәсәнә —
сүтелгән бер җөй дә
чыгарадыр көйдән.
Үпкәләмәсәнә!

ТАТАРСТАН ХАТЫННАРЫ

Җирнең һәммә асылташы,
көмеше, алтыннары
читтә торсын сез булганда,
Татарстан хатыннары!

Безне куркытмый язмышның
яңгыры, салкыннары
сезнең кочагыгыз барда,
Татарстан хатыннары!

Җирдә күпме сайрар кош бар —
аларның хак моңнары
сезнең пышылдауга тормый,
Татарстан хатыннары!

Сез пешергән ризыклардан
тәмлерәк тәгам бармы?!
Булса да, бик сирәктер,
Татарстан хатыннары!

Һәммәгез булырга лаек
шагыйрьләр, ханнар яры —
сез акыллы да, назлы да,
Татарстан хатыннары!

Көзнең җимешләре бит сез,
ә кышның ап-ак кары,
яз гөлләр, җәй рәхәте —
Татарстан хатыннары!

Якты көнле, тәмле төнле,
сез алиһәләр пары!
Яшәгез һәм яшәтегез,
Татарстан хатыннары!

КЕШЕ КАЙЧАН МАТУР?

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта —
Башкаларны чакырганда
Үзе яккан учакка;
ятлар белән танышканда
күзләре җылынганда;
шул җылылыкның рәхәтен
җаның белән тойганда.

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул чакта —
ерак дустын очраткачтын,
елаганда кочаклап;

Җырлаган чакта җырының
моңында эрегәндә;
бәхеткә таба чапканда,
күршеңә юл биргәндә.

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә —
шигырь тыңлаган чагында
уйга чума белгәндә;

Мәхәббәтен сүзсез генә
аңлаткан мизгелендә;
бәхет белән сөйләшкәндә
бәхетнең үз телендә.

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул мәлдә —
иң авыр минутында да
тормышка гашыйк хәлдә;

сөйгән ярын югалтса да,
сөюен саклаганда;
иң “гөнаһлы” гыйшыкның да
сафлыгын аклаганда.

Кеше кайчан матур була?
Кеше матур шул вакыт —
ил өчен, халкы өчен
яшәгәндә җан атып;

замананың авырлыгын
җилкәсенә алганда;
олы данга ирешеп тә,
кече булып калганда.

ТАБЫН

Ничәнче тапкыр тагын
дусларны җыйды табын.
Бер сөйләшик — искә төшсен
гомернең төрле чагы.

Бер көлешик — күңелләрне
йолдызларга күтәрик,
борчуларны болыт итеп,
диңгезләргә түнтәрик!

Сагыну нурына чумыйк,
бераз яктырып калыйк —
бер генә мизгел булса да
саф сабый булып алыйк!

Җырлашыйк җырлый белсәк тә,
белмәсәк тә җырлашыйк —
җыр бит эчкәре дөньядан
тышкарыга нур ташый.

Бизик әле дөньяны бер
табыннар яме белән —
күктән йолдыз тел шартлатсын,
җирдән үрелеп — үлән!

Уйна да, уйла да!

ЯКТАШЛАРЫБЫЗ – ОЛИМПИЯ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ


Фехтование


Велоспорт



Биатлон


Велоспорт


Җиңел атлетика


Җиңел атлетика



Фехтование


Авыр атлетика


Нәфис гимнастика


Җиңел атлетика


Авыр атлетика



Футбол


Җиңел атлетика


Стендка ату


Нәфис гимнастика

Буй шакмакларга Олимпия уеннары җиңүчеләренең – Татарстан спортчыларының фамилияләрен языгыз һәм аркылы юлда допингка каршы көрәш нәтиҗәсендә килеп чыккан яңа уен исемен языгыз.



Җаваплары: 1. Князева. 2. Ганиев. 3. Әхәтова. 4. Лихачёв. 5. Зарипова. 6. Мигунова. 7. Гыйләҗева. 8. Курынов. 10. Нуретдинова. 11. Колесников. 12. Дасаев. 13. Сәмитова. 14. Мосин. 15. Никонова. 16. Горбунова.

Рәсемдә ун хата тап



Фото: David Gatlenfelder/AP





САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

(СКОРПИОН)

№ 14 2016

Журнал айга бер тапкыр рус һәм татар телләрендә чыга.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры, баш редактор Рафаэль ХӘЛИЛУЛЛОВ

Баш редактор урынбасары: Ринат АБЗАЛОВ
Баш редактор урынбасары, баш рәссам: Александр АЛЕШИН
Үсеш бүлеге мөдире: Павел СТАРОВЕРОВ
Җаваплы секретарь: Гөлнара ЗАМАЛДЫНОВА
Бүлек редакторлары:
Людмила САФИУЛЛИНА
Артём СУББОТКИН
Лилия ӘХМӘТОВА
Алмаз ХӘМЗИН
Гузель СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Ләйсән ФӘЛАХОВА

УЧРЕДИТЕЛЕ: «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итүче Федераль служба (Роскомнадзор) идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты: Эл № ФС77-61789 18 май 2015 ел
Нәшер итүче: **АО «ТАТМЕДИА»**
Адрес: 420047 Казан, Академическая ур., 2

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.



татмедиа

Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 222-06-00, тел./факс: 222-05-54.

16+

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan.su

Редакциянең адресы: Декабристлар ур., 2, ТР, Казан, 420066

Люция ӘБЛИЕВА

«Тормыш режиссёры»

Көзгедән миңа томырылып карап торган кешене таныр өчен күзләремне йомдым. Юләр, күз йомып, кеше танып буламыни инде? Ачтым. Юк, үтерсәң дә, танымыйм бу кешене. «Син кем?» дип сорыйсы килә килүен, тик каһәр генә төшсен, эндәшеп булмый, тавыш чыкмый. Кем бу, күз буучымы, бурмы, йә булмаса берәр изгеме? Минем җәфаланганны сизепме, башка сәбәп беләнме, беренче булып ул эндәште:

— Мин — синең «Тормыш режиссерың!»

— Ә?! Тормышның да (җитмәсә, минеке бит әле!) режиссеры буламыни?

— Ник булмасын, син бит мине үзең тудырдың.

Тукта, брат! «Тормышымның режиссеры» булганына ышанырга да риза, тик менә аны тудырганыма... Юк, юк, монысы инде була торган эш түгел!

— Нәрсә? Мин сиңа хатын-кызмы әллә, тудыру эшләре белән шөгыльләнергә. Кем син, ничек минем көзгегә кердең? — димен, тавышыма шактый гына усаллык чаткылары кертеп.

— Мин синең белән шаярырга бала-чага түгел ич, — дигән була. Вәт, имансыз!

Полиция чакырыр идең, кесә телефоным кесәдә юк булып чыкты, җитмәсә, фатирда да берүзем генә булганына төшендем. Булды, болай булгач, мин әйтәм, бетте баш, калды муен серәеп!

Тегеңә күз салам. Тукта, тукта бу бәндә белән без бер-беребезгә охшашып торабыз түгелме соң?

— Әлбәттә, охшашбыз, — ди бу, минем уйларымны укыгандай, — һәркемнең «Тормыш режиссеры» үзенә охшаган була, тик кайберәүләр аны танырга гына теләми.

Инде әзрәк ияләштем димме, курку-аптырау хисе чигендеме, якынрак килдем. Әстәгъфирулла, күзләр дә бертөсле, уң бит очында шул ук миң, килеш-килбәт тә бертөрлерәк, борын тучны минеке инде — ямшек! Вот, сиңа, мә!

— Ах, синмени әле ул институтның беренче курсында ук укуны ташларга ярдәм итүче, ничә ел йорт салдырып бетертмәүче! Тагын, тагын... — тагын бик күп булган һәм булмаган гаепләрне тезәргә исәбем бар иде барлыгын, тик аякларым камырланып, идәнгә лып итеп утырдым да, күзләремне йомдым.

Бераз хәл кергәнен тойгач, инде бу «Тормыш режиссерым» дигәне югалгандыр дигән өмет белән, көзгегә карыйм. Шунда икән, шельма, позициясен генә үзгәрткән — ул да минем кебек, идәнгә җәелеп утырган. Хәзер, хәзер... Кулларым белән нидер эзли башладым, берәр нәрсә килеп эләксә, көзгене бәреп, тегене чәлпәрәмә китерәм. Нәрсә, бер көзгелек кенә акча тапмас дисеңме мине?!

— Хәмидулла, кулларыңны бутама әле шулкадәр, болай да бөтен караватны биләгәнсең!

Тукта, «Тормыш режиссерым» хатын-кыз тавышы белән сөйли башлады түгелме соң? Җитмәсә, төрткәли.

Нәрсә булып бетте дисезме? Нәрсә булсын инде, хатынның шулкадәр төрткәләвенә уянып киттем! Ул арада будильник та шалтырады. Мин төш белән өн арасында буталган арада, хатын:


— Йә, тор, нәрсә иркәләнеп ятасың сабый бала кебек. Марш душка! — дип, беренче маршрутыма «указание» биреп тә өлгерде.

«Тормыш режиссерым» белән сүз көрәштереп азапланмыйм мин, җәмәгать, маршладым душка!



Виктор ФЁДОРОВ

Уйна да, уйла да!



Ринат АБЗАЛОВ төзеде.



1. Бик еш хатыннар алыштыра торган ир русча ничек дип атала?

2. Ни өчен колбаса “докторская” дип атала?

3. Ни өчен Филяның, Каркушаның һәм Степашканың күзләре шундый зур?

4. Рәсәй жыелма команда футболчысы пираттан ничек аерыла?

5. Займ бирүче кешегә русча ничек эндәшергә?

6. Ни өчен СССРда туңдырма бик тәмле булган?

7. Балыкка йөрү нәрсә ул?

ЖАВАПЛАР

1. Частотел. 2. Аны ашаганнан соң, доктор әле бу кешене терелтә ала. 3. Сез яңа алып баручыны күрдегезме? 4. Пиратның бер генә аягы агач. 5. Ссударь. 6. Аңа пальма мае кушылмаган, ул чын сөттән эшләнгән булган. 7. Допинг кулланып үткәрелә торган бердәнбер спорт төре.

Сынамышларны Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА әзерләде.

Чаянвордны чишегез, номерланган шакмакларда ике жыр исемен укыгыз. Журналыбызның 13 нче санында басылган чаянвордның тикшеру сүзләре – **«ГАЛИГӘ БАРАМ ӘЛЕ», «ШӨГЕР».**

Беренче булып дөрес жавап жибәрделәр:


Р. ГАДЕЛШИН (Арча р-ны, Айван ав.),
Ә. ГАРИПОВА (Әлки р-ны, Салман ав.),
Р. ЗАҺРИЕВ (Кукмара р-ны, Югары Арбаш ав.),
М. МИҢНЕМУЛЛИНА (Балтач р-ны, Норма ав.),
С. ШӘЙХУЛЛИН (Казан).

Жиңүчебез – Норма авылыннан **Мәгъфүрә МИҢНЕМУЛЛИНА!**






Вячеслав ШИЛОВ



Василий АЛЕКСАНДРОВ



Валерий ТАРАСЕНКО



Владимир СОЛДАТОВ







